ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«10» январь 2024 ел                                                    № 1

**Арча муниципаль районының Инвестицион советын төзү турында**

«Татарстан Республикасында инвестицион эшчәнлек турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының Инвестицион советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Татарстан Республикасы Президентының Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында инвестицион климатны яхшырту максатыннан, КАРАР БИРӘМ:

1. Арча муниципаль районының Инвестицион советын төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Арча муниципаль районының Инвестицион советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

2.2. Арча муниципаль районының Инвестицион советы составын (2 нче кушымта).

3. «Арча муниципаль районы башлыгы каршында Инвестицион совет төзү турында» Арча муниципаль районы башлыгының 2014 елның 10 апрелендәге 61 номерлы карарын (2015 елның 11 февралендәге 26 номерлы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Н. Габделгазизовка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы                                    И.Г.Нуриев

*Арча муниципаль районы башлыгының*
*10 январь 2024 ел, №1 карарына*
*1 нче кушымта*

**Арча муниципаль районының Инвестицион советы турында нигезләмә**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Арча муниципаль районының Инвестицион советы (алга таба - Совет) Арча муниципаль районы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) таяна.

1.3. Советның төп максатлары:

- Арча муниципаль районында уңай инвестицион климат булдыру;

- инвестицион климатны яхшырту чараларын эшләү, Арча муниципаль районы территориясендә инвестицион эшчәнлек алып баруның һәм инвестицион проектларны гамәлгә ашыруның тотрыклы шартларын тәэмин итү;

- инвестицион эшчәнлек алып баручы субъектларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

- Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча вәкаләтле оешмалар белән инвесторларның каршылыкларын һәм бәхәсләрен судка кадәрге тәртиптә хәл итү.

**II. Советның төп бурычлары**

Советның төп бурычлары:

-район территориясендә районның социаль-икътисади үсеше максатларына һәм өстенлекләренә туры килә торган бердәм инвестицион сәясәт формалаштыру һәм аны гамәлгә ашыру;

- район территориясендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыруда инвестицион эшчәнлек алып баручы субъектларга ярдәм күрсәтү;

- район территориясендә инвестицион проектларны гамәлгә ашырганда административ каршылыкларны бетерү чараларын эшләү, шул исәптән, район территориясендә инвестицион эшчәнлек өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча предприятиеләр һәм оешмалар белән үзара эшчәнлек механизмнарының нәтиҗәлелеген арттыру;

- муниципаль эшчәнлекне гамәлгә ашыруга һәм инвестицион эшчәнлекне стимуллаштыруга бирелә торган бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

- район территориясендә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән инвестицион проектларны гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булуын һәм аларны финанслауның зарурлыгын (мөмкинлекләрен) тикшерү һәм анализлау;

- муниципаль-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү һәм районда муниципаль-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән башка бурычларны хәл итү;

- җир законнары нигезендә инвесторларга җир кишәрлекләрен бирүгә бәйле мәсьәләләрне карау;

- инвестицион проектларны гамәлгә ашыру барышын һәм нәтиҗәләрен тикшерү.

## III. Советның функцияләре

Совет үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

а) түбәндәге тәкъдимнәрне эшләү:

инвестицион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру кысаларында район территориясендә объектлар урнаштыру;

рөхсәт документларын бирү процедурасын кыскарту һәм гадиләштерү өлешендә административ каршылыкларны киметү;

б) инвестицион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашырганда районның һәм инвесторларның бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карау;

в) инвестицион проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен анализлау;

г) районда инвестицион эшчәнлекне регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар проектларын кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү.

## IV. Советның хокуклары

Үз компетенциясе чикләрендә йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне үтәү өчен Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1. Совет компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә;

4.2. Үз утырышларында Совет компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне карарга һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;

4.3. Оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә муниципаль район башкарма комитеты, муниципаль берәмлекләр, оешмалар һәм предприятиеләрнең бүлекләреннән, идарәләреннән Совет бурычларын һәм функцияләрен үтәүне тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

4.4. Аерым инвестицион проектларны эшләү өчен экспертларны һәм консультантларны билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

4.5. Үз утырышларына федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары һәм башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын чакырырга.

## V. Совет эшчәнлеген оештыру

5.1. Совет турында нигезләмә һәм аның составы Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана.

5.2. Совет рәисе булып Арча муниципаль районы башлыгы тора. Совет рәисе аның эшенә җитәкчелек итә, Совет составын раслый, Совет утырышларын алып бара.

Рәис булмаганда, аның вәкаләтләрен Совет рәисе урынбасары башкара.

Совет утырышларын әзерләү эшләрен оештыру һәм утырышларда кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп тору Совет секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Секретарь Совет рәисе һәм аның урынбасары тарафыннан Совет эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча бирелгән йөкләмәләрне үти, Совет составы буенча Совет рәисенә тәкъдимнәр кертә. Совет секретаре булып Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы тора.

5.3. Совет составына Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты, район идарәләре, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы МКУ, Арча муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы, Арча муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешма вәкилләре керә. Билгеләнгән тәртиптә Совет составына килешү буенча эшкуарларның һәм эш бирүчеләрнең киңәш бирү тавышы хокукына ия иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре керергә мөмкин.

Инвестицион процесс субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар Совет рәисенә Совет составына кертү өчен кандидатуралар буенча үз тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

Совет эшендә, кирәк булганда, Совет составына кермәгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре катнаша ала.

5.4. Совет үзенең эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителә торган һәм Совет рәисе раслаган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

5.5. Совет утырышлары кирәк саен үткәрелә, әмма кварталга кимендә бер тапкыр. Утырышларның көн тәртибен һәм аларны үткәрү тәртибен Совет рәисе билгели.

5.6. Совет утырышлары, әгәр аларда Совет әгъзалары составының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

5.7. Совет карары Совет утырышында катнашучыларның ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм Совет секретаре имзалый һәм Совет рәисе раслый торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булганда, Совет рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Совет рәисе булмаган очракта, Совет рәисе урынбасары хәлиткеч тавышка ия. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Совет әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

Утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда Совет әгъзалары бертигез хокукларга ия.

5.8. Совет эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итүне Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башкара.

*Арча муниципаль районы башлыгының*
*10 январь ел, № 1 карарына*
*2 нче кушымта*

**Арча муниципаль районының Инвестицион советы**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Нуриев<br>Илшат Габделфәртович | - Арча муниципаль районы башлыгы, Инвестицион совет рәисе; |
| Габделгазизов<br>Инсаф Нурсилович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Инвестицион совет рәисе урынбасары; |
| Галимуллина<br>Гүзәл Харисовна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы, Инвестицион совет секретаре; |
| Совет әгъзалары: | |
| Абдуллин<br>Ленар Илсурович | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Галимова<br>Светлана Петровна | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Касыймов<br>Рөстәм Фәритович | - «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Миндубаев<br>Тәлгать Җәүдәтович | - «Водоканал-Сервис» ҖЧҖ директоры, «Тепло-Сервис» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Нигъмәтҗанова<br>Олеся Игоревна | - Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының инвестицион проектларга ярдәм итү һәм ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Нурмөхәммәтов<br>Нияз Фәритович | - Идел буе электр челтәрләре «Челтәр компания» АҖ филиалы Арча РЭС башлыгы (килешү буенча); |
| Сабиров<br>Илшат Әнәсович | - Арча РЭГС башлыгы (килешү буенча); |
| Сафиуллина<br>Лилия Рафаилевна | - Арча муниципаль районындагы «Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» МККның төбәк вәкиле (килешү буенча); |
| Сиражиев<br>Илһам Гаптелнурович | - Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хәбиров<br>Айрат Фиркатович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Хәсәнов<br>Илнур Мәхмүтович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Шәрәфетдинов<br>Зөлфәт Зөфәрович | - Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать вәкиле (килешү буенча). |